**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «29» декабреннән

№ 5-33

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-136 номерлы, 2022 елның 8 апрелендәге 20-161 номерлы, 2023 елның 26 маендагы 34-272 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 38-310 номерлы, 2024 елның 23 октябрендәге 49-379 номерлы, 2025 елның 17 апрелендәге 53-410 номерлы, 2025 елның 5 июнендәге 57-437 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктыдагы 9 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9) ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген башкаручы затлар, төбәк операторлары, төзүчеләр, күпфатирлы йорттагы бүлмәләрнең милекчеләре белән турыдан-туры идарә итүче затлар, күпфатирлы йорттагы гомуми милекне карау һәм (яки) ремонтлау эшләрен башкару буенча хезмәтләр күрсәтү турында килешүләр төзегән затлар, күпфатирлы йорттагы бүлмәләрнең милекчеләре

тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләр;».

1.2. Әлеге карар 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы                    Е.А. Тарнавский